ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_09.06.2021__ М ө с л и м № _251_

**«2021 елга Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 февралендәге 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативларын үзгәртү зарурлыгына бәйле рәвештә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2021 елга Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2021 елның 11 февралендәге 45 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның 4 нче кушымтасындагы 2 пунктын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә:

**«2. ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ КҮЛӘМНӘРЕ НОРМАТИВЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ 2021 ЕЛГА МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАЛАРЫН ҺӘМ ЯШЬЛӘРЕН ЯЛ ИТҮ ҺӘМ САВЫКТЫРУ ПРОГРАММАСЫ КЫСАЛАРЫНДА УЗДЫРЫЛА ТОРГАН ЧАРАЛАР**

| Чаралар исемлеге | Уздыру вакыты | Балалар саны | Оештыру өчен җаваплы (башкаручы) |
|---|---|---|---|
| Дәүләт хакимияте, дәүләт органнары, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру | 10.06.2021-30.06.2021 | 60 | «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе», «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБУ |
| «Урман иле» стационар-сәламәтләндерү | 07.07.2021-24.07.2021 | 60 | «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе», |

| | | | |
|---|---|---|---|
| лагеренда профильле смена оештыру | | | МБУ «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» |
| «Урман иле» стационар-сәламәтләндерү лагеренда профильле смена оештыру | 27.07.2021-02.08.2021 | 60 | «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе», «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБУ |
| «Урман иле» стационар-сәламәтләндерү лагеренда профильле смена оештыру | 05.08.2021-14.08.2021 | 40 | «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе», «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБУ |

1.2. 1 нче кушымтаның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комиссия эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эчке эш планы нигезендә башкара.»

1.3. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составын яңа редакциядә расларга (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л. М. Харисовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе Р.Т.Демидов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 11 февралендәге
45 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча
ведомствоара комиссия составы**

| | | |
|---|---|---|
| Бәдретдинова М.Р. | - | Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары - ***комиссия рәисе;*** |
| Харисова Л.М. | | Мөслим муниципаль районының мәгариф идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы - ***комиссия рәисе урынбасары;*** |
| Җаббаров И.Р. | - | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге башлыгы - ***комиссия рәисе урынбасары;*** |
| Шәймарданова Э.Д. | - | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБУ директоры урынбасары - ***комиссия секретаре.*** |

***Комиссия әгъзалары***

| | | |
|---|---|---|
| Гарипов Р.Г. | - | Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Бубекова Н.А. | - | Мөслим муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Якупов Р.Н. | - | «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Бадртдинов А.К. | - | Мөслим муниципаль районы «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБУ директоры (килешү буенча); |
| Әфләтүнов А.Д. | - | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Мөслим районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Мөхәмәтҗанов Р.И. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мамышов Р.М. | - | «ТР буенча Федераль янгынга каршы хезмәт отряды 15 отряд 123 Янгын коткару өлеше» |

ФДКУ башлыгы (килешү буенча);

| | | |
|---|---|---|
| Гараев И.Р. | - | «Татавтодор» ААҖ Минзәлә филиалының Мөслим участогы башлыгы (килешү буенча); |
| Салихҗанов И.Ф. | - | «Мөслим муниципаль районы Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы; |
| Афзалова Р.Р. | - | «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Мөслим-информ» җитәкчесе (килешү буенча); |
| Шамсивалиева А.С. | - | Мөслим муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре; |
| Заһидуллин И.Р. | - | «Мөслим инженерлык челтәрләре» ААҖ директоры (килешү буенча); |
| Мөхәметдинов Д.З. | - | «Мөслим муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ директоры (килешү буенча); |
| Кашапов М.И. | - | «Хуҗалык белән тәэмин итү» МУП директоры (килешү буенча); |
| Сәлимгәрәев К.С. | - | Әлмәт электр челтәрләре «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы «Мөслим РЭС» башлыгы (килешү буенча) |